**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2021 елның 10 ноябре** **№4**

**Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Үрәсбаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 24 ноябренә 11 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Үрәсбаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Үрәсбаш авылы, Пионер урамы, 21 йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

1. 2021 елның 24 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Үрәсбаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Үрәсбаш авылы, Пионер урамы, 21 йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Iтөркем инвалидлары һәм 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Үрәсбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Үрәсбаш авылының Октябрь һәм Пионер урамнарына асфальт салу; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Үрәсбаш авылы юлларында чокырларны ямау; проект-смета документлары;
- Үрәсбаш авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- янгын сүндерү машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);
- урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу?

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Түбән Үрәс авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы: Р.Х. Шамеев